КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 17 октябрь г.Казань № 915

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Гражданнарның федераль законнар белән билгеләнгән категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» төп чарасын Татарстан Республикасында тормышка ашыру турында» 2008 ел, 28 март, 201 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Гражданнарның федераль законнар белән билгеләнгән категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» төп чарасын Татарстан Республикасында тормышка ашыру турында» 2008 ел, 28 март, 201 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 31 август, 740 нчы, 2016 ел, 27 декабрь, 1005 нче; 2018 ел, 26 февраль, 120 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен

түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру турында»;

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 ел, 30 декабрь, 1710 нчы карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын Татарстан Республикасында тормышка ашыру максатларында (алга таба – ведомство максатчан программасы) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

1 – 3 пунктларда «төп чаралар» сүзләрен «ведомство максатчан программалары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Гражданнарның федераль законнар белән билгеләнгән категорияләрен торак белән тәэмин итү буенча дәүләт йөкләмәләрен үтәү» төп чарасын тормышка ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын рәсмиләштерү һәм бирү тәртибен яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2008 ел, 28 март, 201 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 17 октябрь, 915 нче
карары редакциясендә)

«Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру
кысаларында дәүләт торак сертификатларын рәсмиләштерү һәм бирү
тәртибе

1. Бу Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм реализацияләү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 ел, 21 март, 153 нче карары белән расланган «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының «Торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын тормышка ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын чыгару һәм реализацияләү кагыйдәләре (алга таба – Кагыйдәләр) нигезендә эшләнде.

2. Бу Тәртип Татарстан Республикасында «Россия Федерациясе гражданнарын һәркем алырлык һәм уңайлы торак һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин итү» Россия Федерациясе дәүләт программасының « Торак белән тәэмин итүдә һәм торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләүдә гражданнарга дәүләт ярдәме күрсәтү» ведомство максатчан программасын (алга таба тиешенчә – ведомство максатчан программасы, дәүләт программасы) тормышка ашыру кысаларында дәүләт торак сертификатларын (алга таба – сертификатлар) рәсмиләштерү һәм бирү эшен оештыруга кагыла.

3. Ярдәмче программаны тормышка ашыру кысаларында сертификатларны рәсмиләштерүгә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимият органы – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык).

4. Министрлык түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары тарафыннан кертелгән исемлекләр нигезендә планлаштырыла торган елга сертификат алырга теләк белдергән гражданнарның җыелма исемлеген формалаштыруны, раслауны һәм Ярдәмче программаның дәүләт заказчысына кертүне;

планлаштырыла торган елда сертификат алучы гражданнарның җыелма исемлеген һәм шул ук елда сертификатлар алу өчен резервка кертелгән гражданнарның җыелма исемлеген формалаштыруны һәм раслауны;

сертификатлар чыгару өчен Ярдәмче программаның дәүләт заказчысына заявкалар бирүне;

үз компетенциясе чикләрендә сертификатлар алуны, исәпкә алуны, саклауны һәм юкка чыгаруны;

җирле үзидарә органнарыннан планлаштырыла торган елда сертификатлар алучыларның расланган исемлекләренә һәм резерв исемлекләренә кертелгән Ярдәмче программада катнашучы гражданнарның алар тарафыннан формалаштырылган һәм расланган исәпкә алу эшләре күчермәләрен алуны;

эшләп бетерү өчен исәпкә алу эшләренең комплектланмаган күчермәләрен җирле үзидарә органнарына кире кайтаруны;

сертификатлар бланкларын Ярдәмче программада катнашучы гражданнар исеменә рәсмиләштерүне;

бирелгән сертификатлар реестрларын алып баруны;

аны алыштырганда яңа сертификатны билгеләнгән тәртиптә рәсмиләштерүне;

сертификатларны өстәмә чыгару өчен заявка формалаштыруны һәм аны Ярдәмче программаның дәүләт заказчысына кертүне;

бирелгән сертификатлар реестрларыннан өземтәләрне рәсмиләштерүне һәм Ярдәмче программаның дәүләт заказчысына бирүне.

5. Сертификатлар алучы гражданнар исемлегенә һәм гражданнарның резерв исемлекләренә кертелгән гражданнарның исәпкә алу эшләрен формалаштыру, сертификатлар бланкларының икенче ягын тутыру һәм Ярдәмче программада катнашучы гражданнарга сертификатлар тапшыру Кагыйдәләр нигезендә Татарстан Республикасының җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6. Сертификатлар бланкларын алу, саклау һәм юкка чыгару законнар белән билгеләнгән тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.

Сертификатларның тутырылмаган бланкларын саклау Министрлык тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Тутырылган бланкларны саклауны җирле үзидарә органнары башкара.